**ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА, АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ**
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮ, ӘЙЛӘНЕШЕ ҺӘМ СЫЙФАТЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ КОНТРОЛЕН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ**
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясе)

# ПРИКАЗ

30.06.2020 №10-07/48

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 2017 елның 24 ноябрендәге 12-07/200 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең норматив актларын юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар эшчәнлегенә дәүләт контролен гамәлгә ашыруны регламентлаучы Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатыннан чыгып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 24 ноябрендәге 12-07/200 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 2019 елның 26 сентябрендәге 10-07/161 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Административ һәм суд практикасы бүлегенә (Б.Г.Эйдинов) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе урынбасары Р.А.Арслановка йөкләргә.

Җитәкче Җ. .Й.. Әхмәтханов

Татарстан Республикасы
Дәүләт алкоголь
инспекциясенең 30.06.2020
№ 10-07/48 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 2017 елның 24 ноябрендәге 12-07/200 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан алкогольле һәм спиртлы продукцияне ваклап сату өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 нче бүлектә:

2.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте башкача билгеләмәгән булса, 2020 елда «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 209-ФЗ номерлы федераль закон) 4 статьясы нигезләмәләре нигезендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына кертелгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата тикшерүләр 294-ФЗ номерлы федераль законның 26.2 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольлекне гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында һәм дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контрольлек органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата ел саен планлы тикшерүләр уздыру планнарын әзерләү кагыйдәләренең 7 пунктына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 3 апрелендәге 438 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 438 номерлы карары) таләпләре нигезендә оештырыла һәм уздырыла.».

«Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата белдерелә торган зарури таләпләр исемлеге» дигән 2 нче таблицаның 1 нче бүлегендә:

2 нче графаның 1.19 пунктының беренче абзацында «оешмалар» сүзен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле $1.19^1$ пунктын өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 1.19[1] Күпфатирлы йортларда һәм (яки) алар янәшәсендәге территорияләрдә урнашкан җәмәгать туклануы объектларында җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтелгәндә алкогольле продукцияне ваклап сату килгән кешеләргә хезмәт күрсәтү өчен гомуми мәйданы кимендә 20 квадрат метрлы залы булган җәмәгать туклануы объектларда гына рөхсәт ителә. Килгән кешеләргә хезмәт күрсәтү залының мәйданы дигәндә әзер кулинария продукциясен, кондитер эшләнмәләрен һәм (яки) сатып алына торган товарларны куллану өчен билгеләнгән, җәмәгать туклануы объектының махсус җиһазландырылган бүлмәләренең инвентарьлаштыру һәм хокук билгели торган документлар нигезендә билгеләнә торган мәйданы аңлашыла. | 171-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы 4[1] пункты | Планнан тыш тикшерү барышында тикшерелә; хезмәт күрсәтү залы мәйданын раслый торган тиешле инвентарьлаштыру һәм хокук билгели торган документ |

5 нче бүлектә:

5.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.9. Россия Федерациясе норматив хокукый актларында башкача каралмаган булса, еллык План нигезендә планлы тикшерү уздыру вакытының килеп җитүе административ процедураны башлап җибәрү нигезе булып тора.»;

5.23 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.23. Россия Федерациясе норматив хокукый актларында башкача каралмаган булса, еллык План нигезендә планлы тикшерү уздыру вакытының килеп җитүе административ процедураны башлау нигезе булып тора.»;

5.38 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.38. Россия Федерациясе норматив хокукый актларында башкача каралмаган булса, әлеге Регламентның 2.14, 2.15 пунктларында каралган очракларның барлыкка килүе административ процедураны башлау нигезе булып тора.»;

5.49 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.49. Россия Федерациясе норматив хокукый актларында башкача каралмаган булса, әлеге Регламентның 2.10, 2.14, 2.15 пунктларында каралган очракларның барлыкка килүе административ процедураны башлау нигезе булып тора.».